| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МАЛОМЕМИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КЕЧЕ МӘМИ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.11.2022 Кече Мәми ав. № 55

Җирле салымнар буенча недоимканы, әлеге салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 2019 елның 02 апрелендәге ММВ-7-8/164@ номерлы «Бурычларны һәм пенялар буенча бурычларны, штрафлар һәм процентлар буенча түләнүгә өметсез дип танылган бурычларны исәптән чыгару тәртибен һәм недоимканы, штрафларны һәм процентларны түләтүгә ышанычсыз дип тану шартларын раслаучы документлар исемлеген раслау турында» Федеаль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Җирле салымнар буенча недоимканы, әлеге салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычны (алга таба - бурыч)т үләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

- үлемнән соңгы 6 ай эчендә мираска хокук белдерелмәгән очракта, вафат булганнар яисә вафат булган дип игълан ителгән физик затларның җирле салымнары буенча;

- җирле салымнар буенча бурычка 3 елдан артык булса;

- «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 02 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында каралган, салым түләүчеләрнең бөлгенлек (банкротлык) турындагы эшендә кулланыла торган процедураларда булмаган салым түләүчеләрдә недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлары түләнмәгән очракта, суд приставы тарафыннан башкарма производствоны тәмамлау турында карар чыгаруга бәйле рәвештә мөмкин булмаган очракта;

- җирле салымнар буенча, салым түләүчеләр өчен 2022 елның 01 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча исәпләнә торган недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч;

- Россия Федерациясеннән киткән физик затларда недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч 3 елдан артык вакыт узган вакыттан алып, бурычлының

түләве кире кайтарылырга мөмкин булган мөлкәте булмаганда, җирле салымнар буенча, физик затларның недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлары;

- әлеге недоимканы түләтү срогы тәмамланганнан соң недоимкага исәпләнгән оешмаларның пенялары буенча җирле салымнар буенча бурычлары;

- суд тәртибендә хокуктан файдалануга сәләтсез дип танылган психик тайпылышлары булган затларның недоимкалары, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлары;

- картлар (ветераннар) йортларында яшәүче затларның недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурычы;

- башкарма комитет раслаган очракта, аз керемле физик затларның җирле салымнар буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурычы;

- суд хөкем карары нигезендә һәм ирektән мәхрүм итү урыннарында булган затларга һәм ирektән мәхрүм итү урыннарында булу чорына недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч.

2. Салым түләүченең бурычы исемлеге салым органы тарафыннан әлеге карар һәм салым түләүченең бурычы турындагы салым органы белешмәсе нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге карар бурычлар хасил булганнан соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз йогынтысын кертә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Кече Мәми авыл җирлеге Башлыгы — Е.Н.Алексеева